ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 68-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 68-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 318-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
Социаль сәясәт комитеты
тарафыннан кертелә

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле унҗиденче абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«“Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында”» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның $22^1$ статьясындагы 4 пунктының 1 пунктчасындагы өченче абзацында күрсәтелгән затлар, Татарстан Республикасы территориясендә медицина калдыкларын транспортировкалау, зарарсызландыру хезмәтләрен күрсәтүче затлар хакында белешмәләрне, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм әлеге затлар тарафыннан медицина калдыкларын йогышсызландыру, зарарсызландыру гамәлгә ашырыла торган объектлар исемлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты 2025 елның 1 июленнән үз көченә керәчәк «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 306-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Медицина калдыклары белән эш итү мәсьәләләрен җайга салуны камилләштерү максатларында закон проекты белән «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре хакындагы 3 статьясына медицина калдыкларын йогышсызландыруны гамәлгә ашыручы затлар, Россия Федерациясе субъекты территориясендә медицина калдыкларын транспортировкалау, зарарсызландыру хезмәтләрен күрсәтүче затлар турында белешмәләрне, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм әлеге затлар тарафыннан медицина калдыкларын йогышсызландыру, зарарсызландыру башкарыла торган объектлар исемлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында урнаштыру вәкаләтен өстәү тәкъдим ителә.

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.